ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына “чит ил финанс инструментлары” төшенчәсен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында” 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 пунктының “$б^{2}$” пунктчасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәп: “Әлеге Законда “чит ил финанс инструментлары” төшенчәсе “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәсендә кулланыла.”, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында” 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы $7^{1}$ пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәп: “Әлеге Законда “чит ил финанс инструментлары” төшенчәсе “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан

файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәсендә кулланыла.”, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы 5 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәп: “Әлеге Кодекста “чит ил финанс инструментлары” төшенчәсе “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәсендә кулланыла.”, үзгәреш кертергә.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                        Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2017 ел, 05 июль
№ 46-ТРЗ